ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘТНӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КЫШЛАУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КШКЛОВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ АТНИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422008 Республика Татарстан Атнинский район с. Кшклово. Тел. 3-43-45

# КАРАР

31 май 2024 ел. № 6

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге башкарма комитетының 2021 елның 6 августында 20 номерлы карары белән расланган адресларны бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына үзгәрешләр кертү турында**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында " 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, 2024 елның 05 февралендәге «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 19 ноябрендәге 1221 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында " 124 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Кышлау авыл җирлеге башкарма комитеты карар итә:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге башкарма комитетының 2021 елның 6 августында 20 номерлы карары белән расланган адресларны бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.2 пунктның 10 нчы абзацында. "әлеге пунктта күрсәтелгән зат исеменнән» сүзләрен "гариза белән" сүзләренә алыштырырга";

1.2. 2.3.2 пунктын түбәндәге эчтәлектәге яңа редакциядә бәян итәргә:
"2.3.2. Адреслашу объектына яңа адрес бирелгән очракта адреслашу объектының адресын гамәлдән чыгару турындагы карар әлеге объектка яңа адрес бирү турындагы карар белән берләштерелә.»;
1.3. 2.4.1 пунктын түбәндәге эчтәлектә яңа редакциядә бәян итәргә:
"2.4.1. Адреслашу объектына адрес бирү яки аның адресын гамәлдән чыгару турында Карар кабул итү, адреслашу объектына адреслашудан баш тарту яки аның адресын гамәлдән чыгару турында Карар кабул итү, шулай ук адреслашу объектының адресы турында тиешле мәгълүматны Дәүләт адрес реестрында урнаштыру:
а) кәгазьдә гариза бирелгән очракта - гариза кергән көннән алып 10 эш көненнән дә артык булмаган вакыт эчендә;
б) электрон документ формасында гариза бирелгән очракта - гариза килгән көннән алып 5 эш көненнән дә артык булмаган срокта.» гамәлгә ашырыла.

2. Әлеге карарны авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында игълан итәргә (pravo.tatarstan.ru), шулай ук Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында "Интернет" мәгълүмати-коммуникацион челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.
Кышлау авыл җирлеге башлыгы: Кашшапов А.Х.